Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 март 2019 ел №284

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында»гы Нигезләмә хакындагы 2016 елның 28 декабрендәге №145 карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 27 декабрендәге «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнарын оештыру һәм эшчәнлегенең төп принциплары турында» № 559-ФЗ Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына, 2019 елның 1 мартындагы "Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” № 169-ТРЗ һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 15 статьясына”, 2018 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәт турында» «Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында»гы 2016 елның 28 декабрендәге №145 карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 30 мартындагы № 166, 2017 елның 5 маендагы № 178, 2017 елның 31 маендагы № 184, 2017 елның 25 сентябрендәге № 196, 2018 елның 11 маендагы № 238, 2018 елның 13 декабрендәге № 267 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карардагы кушымтада:

1.1.1. 6 нчы бүлекне «Муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр» түбәндәге эчтәлекле 6.5 пункты белән тулыландырырга:

«6.5.Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән туганлык яки туганлык үзлекләре (ата-аналары, ире, балалары, абыйлары, апалары, шулай ук хатынының абыйлары, апалары,ата-аналары, балаларының хатыны, ире) булган очракта, гражданин муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазифасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазифаларын били алмый»;

1.1.2. 18 нче бүлек «Кадрлар эше» 18.2 пунктының 9 нчы пунктчасын «Килешү нигезендә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләү» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. 18.2 пунктының 8 пунктчасында каралган конкурсны үткәрү турындагы мәгълүматта, уку тәмамланганнан соң гражданнар белән алмаштырырга тиешле муниципаль хезмәт вазифалары төркемнәре күрсәтелә; әлеге вазифаларга квалификация таләпләре; әлеге Нигезләмәнең 18.2 пунктының 11 пунктчасы нигезендә конкурска тапшырыла торган документлар исемлеге, аларны кабул итү урыны һәм вакыты; әлеге документлар кабул ителә торган срок; конкурсны үткәрү датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан укыту турында шартнамә төзүгә кандидатларны бәяләү һәм сайлап алу өчен кулланыла торган конкурс процедуралары күрсәтелә; язма биремнең темасы (конкурс процедураларының конкурс комиссиясе тарафыннан кулланылучы берсе язма бирем булса), шулай ук башка мәгълүмат материаллары да булырга мөмкин».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин